**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Аксар авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 129** **«24» июнь 2024 ел**

**“Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” 2018 елның 25 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Уставы белән, Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. “Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” 2018 елның 25 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советы карарына (Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советының 25.05.2018 №109, 22.09.2020 №6, 30.12.2021 №18, 01.10.2022 №72, 22.11.2022 №75, 01.03.2023 №91 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи

затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренэ, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турынданигезләмәгә:

2.2 пунктта «12 688 сум «сүзләрен» 13 323 сум « сүзләре белән алыштырырга;

2.6 пунктта «18 процент» сүзен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга;

2.14 пунктта «12 688 сум «сүзләрен» 13 323 сум « сүзләре белән алыштырырга;

2.11 пунктның 2 абзацында «64,25 процент» сүзен «118 процент» сүзләре белән алыштырырга;

2.15 пунктның 3 пунктчасында «15 процент» сүзен «37 процент» сүзләре белән алыштырырга.

1.2. Әлеге карар белән расланган "Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренэ, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында" нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аксар авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 19 991 |

2 Карарны Аксар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет Рәисе** **Ю.И.Гыйлманов**